**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Уразаевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Энгельса, д..65, с.Уразаево, 423330
Тел. (8-85592) 43555, факс (8-85592) 43555

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты**

Энгельс урамы. 65, Уразай авылы, 423330
Тел. (8-85592) 43555, факс (8-85592) 43555

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 апрель 2020 ел № 7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 30 нчы гыйнварыннан 1 нче номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында" карары белән расланган административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында (2019 елның 17 нче октябреннэн 37 нче номерлы, 2020 елның 27 нче феврaленнэн 4 нче номерлы карарлар редакциясендә)

2020 елнын 01 мартындагы 35-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 30 нчы гыйнварыннан 1 нче номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында" карары белән расланган административ регламентларга (2019 елның 17 нче октябреннэн 37 нче номерлы, 2020 елның 27 нче февраленнэн 4 нче номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны, муниципаль торак фонды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында

а) 2.5 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) гариза бирүче-гражданның гаилә составы турында документлар күчермәләре (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б.);»;

б) 2.5 пунктынын 5 пунктчасында өченче, дүртенче абзацларны төшереп калдырырга.

1.2. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондыннан торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) гариза бирүче гражданнарның гаилә составы турында документлар күчермәләре (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ.б.);».

1.3. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.4. Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Глава : А.М.Шарифуллина